Саранскида оешма хезмәткәре, интернетта акча эшләv сылтавы белән, 800 мен сумга якын акча югалткан.
Россия Эчке эшләр министрлыгынын Саранск буенча 3нче ОПга мошенниклык турында гариза белән 58 яшьлек жирле хатын-кыз морәжәгать иткән. Хатын полиция хезмәткәрләренә сойләгәнчә, интернет челтәрендә остәмә акча эзләп, vзенен мобиль телефон номерын калдырган битне тапкан. Берникадәр вакыттан сон ана Яна исемле кыз шалтыраткан һәм берничә вакансия тәкъдим иткән. Аннары ул ана аккаунт булдырган һәм биш санлы кодны хәбәр иткән. Саннардан кvрсәтелгән комбинацияне ул онлайн банк кушымтасында керткән, янәсе «эш кабинеты» булдыру очен, анда алга таба, менеджер сvзләренчә, эшләп тапкан акчалар тупланачак. Нәтижәдә кредит картасыннан 190 мен сум акча кvчерелгән.
Аннары сойләшv менеджер Алена белән дәвам иткән. Анын тәкъдиме буенча, әнгәмәне мессенджерда дәвам иткәннәр. Кыз ана морәжәгать итvченен шәхси акчалары булган башка банкнын онлайн кушымтасына керергә һәм аларны «эш кабинеты» счетына кvчерергә кинәш иткән. Нәтижәдә, картадан кvчергәннән сон, 28 322 сум кvләмендә сумма тошереп калдырылган. Мондый процедуралар vткәргәндә стандарт таләпләргә сылтама ясап, әнгәмәдәш хатын-кызны бу унайдан борчылмаска кvндерә. Соныннан Саранскида яшәvче 149 000 сум акча алу очен маркетплейс кушымтасына кvчә, кvрсәтелгән суммага товарны кәрзингә сала һәм тvли. Алга таба тагын берничә финанс операциясе башкарган, шул исәптән, 300 мен сумлык кредит рәсмиләштергән, аларны янәсе анын хезмәт хакы исәпләнә торган счетка кvчерергә тырышкан, әмма счетны блоклаганнар.
Банк хезмәткәрләре килеп туган проблема буенча анын гаризасын карау якынча 10 кон алачак, дип анлатканнар.
Зыян кvрvче, счетны ачуны коткәндә, мошенниклар белән аралашуын һәм полициягә морәжәгать итәргә кирәклеген анлаган. Зыяннын гомуми суммасы 788 604 сум тәшкил итә.
Хәзерге вакытта Россия Эчке эшләр министрлыгынын Саранск буенча идарәсе хезмәткәрләре әлеге факт буенча тикшерv уздыра. Булган хәлнен шартларын һәм жинаятьчеләрнен шәхесләрен ачык-лый.
Тәртип сакчылары исегезгә тоше-рә: телефоннан остәмә керем турында тәкъдимнәр алганда уяу булыгыз, ят кешеләргә ышанмагыз! Мошенниклар даими рәвештә алдаунын яна ысулларын уйлап таба. Аларнын корбаны булмас очен, Мордовия Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы экспертларыннан схемаларны һәм кинәшләрне кvзәтегез.